# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында”**
**Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында” 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“3. Татарстан Республикасы министры вазыйфасы буенча айлык акчалата гомуми хезмәт хакы күләме Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга айлык акчалата гомуми хезмәт хакы күләмнәрен арттыру (индексацияләү) турында карар Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кабул ителә.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.
2. Әлеге Законның гамәлдә булуы 2013 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2013 елның 15 ноябре
№ 91-ТРЗ